

ЧАЯН

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ДЕКАБРЬ * 2016 * КАЗАН

18

Эльвира ДЫШАЕВА



Виталий ПОДВИЦКИЙ



АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Евросоюз Рәсәйгә каршы яңа санкцияләр кертергә чамалый: Украинада узарга тиешле "Европидение" конкурсын Рәсәйгә күчерергә.

Одесса өлкәсенең губернатор кәнәфие өчен көрәш Барак Обама белән Франсуа Олланд арасында килеп чыгарга мөмкин.

Обама АКШның яңа президентына атом-төш чемоданын һәм барлык Рәсәй подъездларының домофон кодларын тапшырачак.

Казанда узачак Конфедерация кубогының жирәбәсе буенча, безнең җыелма командага Португалия, Мексика һәм Яңа Зеландиялеләргә оттыру каралган.

Герман Греф, гарип кеше булып кыланып, Сбербанктан кредит алмакчы булган, ләкин әбиләр аны чиратсыз алга үткәрмәгәннәр.

Фәнни гаҗәпкә калдырышлы ачыш: Луврның борынгы грек фрескаларында Википедиядәге Александр Македонскийның сурәте төшерелгән.

Яценюк Бөек Мексика стенасын төзү буенча Трампның киңәшчесе булырга мөмкин.

Хәрбиләр өчен социаль челтәр булдырылды — ВКонтракте.

Киркоров белән Маруани җәнҗалы мәсьәләсендә: музыкасын болгар урлаган, француз җанҗал куптарган, билгесез пранкерлар шалтыраткан, ә Рәсәй тагын гаепле.

Тыгыз автобус эчендә барганда әби кеше берәүнең сыртына терсәге белән төрткән һәм умырткасын төзәткән.

Таксида барган бер пассажир, таксисттан шансонны классик музыкага алыштыруын үтенеп, авария ясаткан.

Салым хезмәте нәтиҗәләре буенча, офтальмология дәваханәләрнең кереме күзгә күренеп үсеп киткән.

Үзеннән-үзе йөри торган шахмат фигуралары уйлап табылган.

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Тиздән Яңа ел — иң матур гаилә бәйрәме. Ләкин кайбер министрларыбыз, депутатларыбыз һәм олигархларыбыз аны, гадәттә, Альп ял йортларында яки шаккаткыч пляжларда каршылыйлар... Бу юлы алар кайда кәеф-сафа корырлар икән, шуны бик беләсебез килә?

Г. ДАМИРОВА

ӘГЕРЖЕ

Журналыбызны укучы ханымның хатын хөрмәтләребезнең-хөрмәтлесе Шомбай агага күрсәттек.

— Бөтенесе өчен дә җавап бирә алмыйм, ләкин Улюкаев Яңа елны өендә каршылаячагын төгәл әйтә алам, — диде аксакал.

Илдус АЗИМОВ



Эрнест ДЫШАЕВ



Хөрмәтле ханымнар! Мунчаның хатын-кызлар бүлегенә 3 яше тулган ирләрне генә кертергә мөмкин. Аңлавыгыз өчен чын күңелдән зур рәхмәт.

Сочидан 1513 км ераклыкта булган җир бүлеме сатыла. Казан тирәсендәге экологик яктан чип-чиста урын.

15 ноябрьдә Мәдәният сараенда мондагы җылы кием җитештерүчеләрнең күргәзмә-сатуы оештырыла.

Хөрмәтле ата-аналар! Мәктәп бинасына аек булмаган килеш керү тыела. Вакытлыча уңайсызлык тудырганыбыз өчен гафу үтенәбез.

(белдерүләр)



Михаил ЛАРИЧЕВ



Рашат НИЗАМИ

ХИКМӘТЛЕ БАЗАР

Беркөн шулай ял көнендә
Базарга барган идем.
Андагы тамашаларны
Күреп таң калган идем...

Җиләк-җимеш, өрекләрен
Мактый Кавказ агасы.
Сөт-катыгын киштәләргә
Тезгән татар апасы.

Түтәйләрнең көнбагышын
Чүпли базар чыпчыгы.
Мыеклы бер абый бара –
Аркасында капчыгы.

Чү, бу нинди "тере" капчык!
Кыймылдый да селкенә...
Ә эченнән мыркылдаган
Сәер аваз ишетелә.

Җиргә куйды да капчыкның
Өстен җибәрде ачып, –
Теп-тере чучка баласы
Тора аякта басып!

Интернет аша — зәһәр

Җинаятьче халкы хәзер төшеп калганнардан түгел. Акыл-белем ягыннан да, эшчәнлеген җиһазландыру ягыннан да. Наркотиклар белән сәүдә итүчеләрне генә алыйк. Товар ясау өчен ингредиентларны алар Интернет аша гына эзлиләр. Хәтта үлчәүләре дә борынгы аптека үлчәве түгел, ә төгәлдән дә төгәл электроника. Клиентларны да төнге клубларда һәм ишегалларында түгел, ә Бөтендөнья челтәрендә табалар. Һәм иң мөһиме — дистанцион рәвештә эшлиләр. Товарны кулдан-кулга түгел, ә махсус яшерен урыннар аша тапшыралар. Нәкъ шпионнар турындагы фильмнардагы шикелле! Зәһәр сатучылар, мондый конспирация белән аларны полиция түгел, шайтан үзе дә таба алмас, дип уйлыйлар!

Түбән Камада яшәүче Федонин атлы бәндә дә шулай фикер йөрткән. Ул наркотиклы порошокларны "контактсыз" тарату буенча сәүдә челтәре оештырган. "Химия" белән киң колачлы рәвештә сәүдә иткәннәр — алар нефтехимия башкаласын гына түгел, ә бөтен Кама арты зонасын үз карамакларына алганнар. Наркотик җитештерүчеләрнең хәвеф-хәтәрсез "эшләү"ләренә ышанычны әлеге дә баягы "контактсыз" ысул биреп торган. Тик барыбер "химик"ларны хикмәтле ысуллар коткарып кала алмаган: хәзер аларга озак еллар буе чәнечкеле тимерчыбык артындагы торакларда яшәргә туры киләчәк.

Шул ук Түбән Камада Хәбибуллин атлы берәү һәм аның иптәшләре дә тайгак юлга басканнар. Сак егетләр, клиентлар белән акча эшләрен башкарганнан соң, аларга Интернет аша товар яшерелгән урын турында хәбәр салганнар. "Наркокибет"кә нәкъ өч ай эшләргә насыйп булган. Сатып алучылар белән гомумән очрашмаган булсалар да, "конспираторлар" барыбер капканнар. Хәзер инде суд булганчы "контактсыз" сәүдәнең нинди нәтиҗәләргә китерүе турында аларның уйланырга мөмкинлекләре бар.

Казаннан 25 яшьлек Эдуард А. да полицейскийлар кулына эләкмәячәгенә нык ышанган булган. Шуңа күрә "товар"ны тиешле урынга куярга чыкканда ярыйсы гына күләмдә наркотик кабул итүне дә артык санамаган. Уңнан сулга боргаланып баручы автомобильне полицейскийлар Казанның Кадышево бистәсендә туктатканнар. Аны тоткарлагач, аягында көчкә басып торучы машина йөртүченең кесәсендә зәһәр салынган пакетлар тапканнар. Җиңел акчага кызыгып, кыек юлга басуына егет хәзер бик үкенәдер инде.

Чаллыдагы 34 яшьлек ханымның машинасында табылган "контактсыз" сату өчен әзерләнгән пакетлар да аның хуҗабикәсенә зур байлык китерә алмаган...

Мондый сәүдә өчен сроклар да кечкенә түгел. Шуңа күрә үзләрен шомарып беткән дип санаучы дилерлар истә тотарга тиеш: наркотиклар белән бернинди "контактсыз" эш итү дә полиция белән очрашудан коткарып кала алмаячак. Бу эштә шайтан да ярдәм итмәс...

Айдар СУБАЕВ



Илдар НӘФИЕВ









• • •

Трамп:

– Мин Россиянең чын дусты, шуңа күрә санкцияләрне беркайчан да туктатмаячакмын, чөнки алар Рәсәй икътисадына бик тә файдалы.

• • •

Иң дәрәҗәле мәктәпләрдә яңадан чыбык белән суктыру тәртибен кертteләр: хәзер гаебе булган укытучыларны олигарх балалары теләсә кайсы вакытта тотып кыйный алалар.

• • •

Түрәне салым бүлегенә чакырып алалар:

– Сез үткән елгы керемнәр декларациясендә 5 миллион табыш алуыгызны күрсәткәнсез, ә безнең белүебезнчә: шул елны 8 миллион чыгым ясагансыз – бу ничек шулай килеп чыга соң?

– Ничек дип инде... Очын очка ялгап булмагач!

• • •

Халык сынамышы: әгәр яңа банк ачылганда аны һава тутырылган шарлар белән бизиләр икән, димәк, ул тиздән шартлаячак.

• • •

Хәзерге сатып алучының кибеткә пакетсыз баруын күрсәгез, аны, бер дә ялгышмыйча, урта сыйныф вәкиле дип санарга мөмкин.

• • •

Якын киләчәк. Оныгы бабасыннан сорый:

– Бабай, мин пенси ятурында хыяллана аламмы?

– Аласың, улым: хыяллану әле тыелмаган, аннан хәтта салым да алынмый хәзергә.

• • •

Ике ир очраша. Берсе икенчесеннән сорый:

– Син бүген балыкка барасыңмы?

– Юк.

– Ә нигә?

– Гороскоптан укыдым: бүген балыклар өчен уңай көн.

• • •

Илледән соң күп хатын-кызның баш авыртуы туктый, һәм алар бөтен нәрсәгә ризалаша, ләкин инде соң була...



ЧЕХОВТАН БЕРАЗ ТАЙПЫЛЫП

Чехов хикәясендәге караңгы һәм мокыт мужик Денис Григорьев балык тоту өчен батыргычлар ясарга тимер юл рельсларыннан гайкалар борып алган. Икенче Денис – «Менделеевсказот» фирмасының тимер юл башлыгы Денис Петров әдәби "адашын" күпкә уздырып җибәргән. Ул Менделеевск янындагы вакытлыча эшләми торган тимер юлдан... рельслар чәлгән. Бер-икене генә түгел, ә ярты километрлы юл участогында ялгыз шпаллар гына калдырып. Озак та үтми киселгән рельсларны һәм аларны шудырткан станция башлыгын тапканнар. Әлбәттә, мондый катлаулы эшне ул үзе генә башкара алмаган булыр иде. Тимер юлны сүтәр өчен ул кешеләр һәм махсус техника яллаган. Тимер карагының "эшчәнлеге" нәтиҗәсендә дәүләткә дүрт миллион сум зыян китерелгән.

«ТҮБӘ" ОПЕРАЦИЯСЕ

Чаллыдагы «Татарстан кешеләре" дип аталган хәйрия фонды Президенты Сергей Изотов йортларда яшәүчеләрнең акчалары ничек тотылганын ачыклар өчен шәһәр ЖКХсына урнашырга булган. Ул өч ай дәвамында «СК КапРемСтрой+» фирмасында гади эшче сыйфатында ЗЯБ бистәсендә 18/12 нче йортның түбәсен ремонтлаган. Шул вакыт эчендә ул квалификациясез эшчеләр кулланауын һәм срогы чыккан төзелеш материаллары файдаланган кебек, күпсанлы тәртип бозуларга тап булган. Сергей үзенең күзәтүләрен язма рәвештә шәһәр мэриясенә юллаган. Фактларны тикшерер өчен комиссия төзелгән. Ләкин объектка килеп җиткәнче ул тәртип бозуларның күбесе серле рәвештә исемлектән юкка чыккан, барлы-юклы бер-ике кечкенә кагыйдә бозу гына калган.

ӘДӘПЛЕ РИШВӘТЧЕЛӘР

Соңгы вакытта Россиядә "өстә утыручы" коррупционерларга каршы җитди көрәш башланды. Ә менә Украинада көрәш урынына... ришвәтчеләрне рәсмиләштерергә булганнар. Оялып-нитеп тормыйча, "Халык фронты" фракциясе Верховный Радага "әдәпле ришвәтчеләр" булдыру мөмкинлеге турында закон проекты керткән. Тарихта күрелмәгән бу төшенчә коррупция нәтиҗәсендә "үз вакытында, закон тарафыннан каралган срокларда декларациясендә активлар, керемнәр һәм башка табышлар турындагы мәгълүматларны чагылдырганнар"га карата кулланылачак. Әгәр закон проекты хуплanса, "башы кыйшайган" хакимият, ичмасам, бу өлкәдә булса да дөньяда беренчелекне яулаячак. Ә гади украинлыларга ришвәт биргән өчен салым түләү турында каршы тәкъдим белән чыгарга була.







Алексей БУЛАТОВ



Эльвира ДЫШАЕВА



Нажия БӘХТИЕВА

Кильки шаукымы

Кешеләр нигә алдашалар? Моның сәбәпләре төрле. Балачакта яшереп куелган "икеле"ләр тулы мәктәп көндәлеге, олылар тормышында "сулга" чыгып йөргән өчен. Игътибар үзәгендә булу, кеше алдында дәрәҗәңне күтәрү өчен. Аучыларның һәм балыкчыларның әкият-хикәятләрен генә исегезгә төшерегез. Үзеңә файда алу өчен махсус алдашу да була: мәсәлән, сайлау алды кампаниясе яисә вак хәрефләр белән җыелган килешенүләр. Ә менә безнең "каһарманыбыз" Сәүбән исә бары кызык өчен алдашкан. Башкача әйтсәк, алдашу өчен алдашкан.

Аның "Мерседес"ларда йөрүче күршеләре Сәүбәннең кар астыннан төртелеп чыгучы парафин тюльпаннары, тәлгәш-тәлгәш асылынып торган пласт-масс помидорлары, мул алма уңышы бирүче миләш куакларына күптән ияләнеп беттеләр инде. Алар моңа елмаеп кына кырыйлар иде. Аның каравы, бу могҗизаларның Интернетка куелган фоторәсемнәре меңләгән "лайк" җыя һәм тылсымлы орлыклар белән бүлешү турындагы үтенечләр белән тулып тора иде.

Сәүбән, бик юмарт хуҗа буларак, кунаклар күп чакыра, һәм бу мул мәҗлесләр гаилә бюджетын авыр йөк булып баса башлаган иде.

Берзаман ул гадәти тәртипне бераз үзгәртергә була. Хатыны, кухняда көтелмәгән кунаклар алдында гафу үтенә-үтенә, мәшәкатьләнеп йөргән арада, Сәүбән кильки консервасы ача башлый. Кунакларга таба борылып, аларга алдан ук кызыл икра тутырып куелган кильки банкасы күрсәтә. Гаҗәпләнү авазлары яңгырый. Барчасы да, тел шартлатып, банканы төрле яктан тикшереп карап, икраны кабып карый. Күбесе аны фотога төшереп, партия номерын язып, кибет адресы белән кызыксына башлый. Шул арада барлык кунакларның да кичектергесез эшләре килеп чыга, һәм алар, этешә-төртешә, юмарт йорттан китү ягын карый.

Икенче көнне иртән кибеттә ике сатучының сөйләшкәнен ишетә.

— Белмим, нәрсә булгандыр, кичә кичен халык акылыннан язган иде. Килькине унбишәр банка алдылар. Үземә дә икене калдырган идем. Кабып карасам — мәче дә иснәми торган нәрсә...

Сәүбән эчтән генә кунаклар өчен шатланып куйды...

Ринат АБЗАЛОВ



Хәнәфи БӘДИГЫЙ

ЛЕНИН һӘМ ХӘМЗИН

Двое в комнате. Я и Ленин
Фотографией на белой стене.
(В. Маяковский. "Разговор
с товарищем Лениным").

Алмаз Хәмзин бүлмәсендә
Ильич рәсеме тора.
Гадәттәгечә, юлбашчы
Яңача план кора;
Хәмзин сизгер: бабай белән
Фикерләшеп утыра.

Рәсем — затлы рамда түгел:
Картон — колашаланган.
Нәкъ Рәсәй күк: акчасы күп,
Ләкин бик нык "йомшарган";
Коррупциядән, байлардан
Таланган, ботарланган.

Хәмзин баш күтәрми эшли:
Укый, сыза, төзәтә.
"Чаян" күзлегеннән карап,
Бу тормышны күзәтә;
Юлбашчыдан үрнәк алып,
Үткен, йомры сүз әйтә.

Ленин аңлый: Хәмзин белә
"Капитал", Фейербахны.
Укый, яза, сөйли; тыңлый
Сәйдәш, Моцарт һәм Бахны;
Хәмзин хезмәт белән яулый
Фани-бакый оҗмахны.

Ильич әйтә: "Архи кирәк
Бер таяну ноктасы.
Яңа тормышка керергә
Ныклы ишек тоткасы";
Хәмзин әйтә: "Туйдырды, — ди, —
Ялган, буш сүз боткасы.

Ул татарга дәүләт биргән
Бердәнбер рус патшасы.
Нокта белән тотка биргән —
Озын сүзнең кыскасы;
Шуны аңлатып бирә ич
Бәдигыйның кыйссасы".

Александр КОСМЫЛИН



Андрей КЛИМОВ



ИНТИМ ЛИРИКА

ХОККУ

Кышкы иртә.
Ләкин моңсу күңел,
Сөю даулап, тиле, талпына.
...Хатынның да
күз карашы уйчан:
Яшьлек мәхәббәтен сагына...

Ринат АБЗАЛОВ

Вәли БАКЫЕВ

ТОГО ИЛЕННӘН ХАТ

Африкадагы Того иленнән безнең авылга хат килеп төште. Инде бездә почта юклыгына бишбылтыр. Ә менә компьютерлы кешеләр – өй саен. Ике ел элек, янгын чыгып бөтенебез янып беткәннән соң, спонсорлар, тактадан эшләнгән өйләребезгә ванналар, көнкүреш һәм компьютер техникалары тутырып киттеләр... Авыл үзгәрде, тормыш алга китте: әбиләр дә, балалар да интернетта казыналар яисә бер-берсенә сәламнәр җибәреп рәхәтләнәләр...

Менә миңа да русчалатып язылган бер электрон хат килеп иреште: "Товариш Абдул Луло (бездә күпләр Габдулла исемле) пишу вас из Того. Я авокадо Макабо Мбу, прикончил учеба Лумумба. В город Манго, месяц назад скончал ваша дядя Абдуллин Абдул Луло Абович. За того и хлопочусь. Совсемь после конца он оставил состояне 10 млн. долл. Я как душеприкажник пустился в розск родственники. И вот нашел. Если ваш согласие присылай 1 тыс. долл. для того, чтоб подтверждать серьезност ваших намерений. Авокадо Макабо Мбу».

Шул ук көннең кичендә тагын шундый хат алган җиде Габдулла ачыкланды. Барыбыз да җыелышып Габдулланың якты истәлегенә дога кылдык. Әлеге Габдулланың кайсы Габдулла икәнлеген ачыкладык. Ул – авылыбызның мишәре – Абдул Абович булып чыкты. Аның райүзәктә сантехник булып эшләп йөргән чаклары бар иде, аннан соң Африкада армия сафларында хезмәт итте, шуннан аны хәрбилектә калдырдылар да инде. Элегрәк язган хатларында берниндә дә миллионерлыгы беленми иде.

Шул хәсрәтләр белән йөргән арада Габдулланың үзеннән электрон хат килеп төште. Акча сорап язган. Үлгән булып чутланса да, бер дә андыйга охшамаган тагы үзе. Исәнлеген кабат шатланып "юдык". Җавап хаты язып салдык, әлегә виртуально акча җибәрергә өйрәнмәдек, дип. Түз инде, дип кенә өстәп куйдык...

"Авокадо"га җавап яздым: "Хөрмәтле иптәш, Мбу! Хатыңны алдым. Сиңа әйтәсем килә: безнең авылда күрәзәче Җамал исемле әби яши. Ул хәтта бер күз төшерү белән җигелгән атны тугара. Менә хәзерге минутта Җамал әби сезгә Абдул Лулоны исән-сау килеш күреп тора. Ләкин ул бик ярлы, ди. Ә сине, киресенчә, бик бай һәм хәйләкәр, ди. Синең үзеңне "күкрәк бакасы" кыса икән. Әгәр дә тереләсең килсә, Җамал әби белән күрешегез, ул сезне бу чирдән коткарыр. Ә хәзергә ул Абдул Лулога акча белән ярдәм итеп торуыгызны сорый. Шулай итсәгез, бу чирдән коткарырга вәгъдә итә. Килегез! Сандугач җәйне көткән кебек, җавап көтәбез".

ЧАЯН СПОРТКЛУБЫ


Валентин ДУБИНИН



Валентин ДРУЖИНИН


Валерий ТАРАСЕНКО



БЕР ФИКЕРГӘ — ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Россия гражданнарының язмышын закон түгел, власть билгели дисәм, дөрес булырмы?

Алмаз Хәмзин: Өчәр, дүртәр срок хакимлек иткән хәкимнәр хәл итә.

Р. Н.: Алмаз туган, син "интернет" белән "инкыйраз" рифмалашкан заманда яшәвеңне беләсеңме?

А. Х.: Беләм. Ә менә син үзең "ришвәт" заманында яшәп, "ишәк" булып рифмалашканыңны беләсеңме микән?..

Р. Н.: Табышмак әйтәм: "Азатлык" дисәң — кача; "толерантлык" дисәң, бот күтәреп кул чаба. Ул кем?

А. Х.: Син аның кем икәнең үзең дә беләсең... Әйтмим.

Р. Н.: Зәңгәр экраннардан өч "герой"ның төшеп торганы юк: Петросян (юмор), Нагиев (реклама), Жириновский (сәясәт). Халык алардан туймады микән?

А. Х.: Ярый әле алар бар, бүтән нәрсә карар идең?..

Р. Н.: Әгәр Казанда 60 этажлы күксөзәр (небоскреб) төзесәләр, син аның иң югары катында яшәргә курыкмас идеңме?

А. Х.: Курыкмас идем — Ходайга якын бит.

Р. Н.: Йөк аты гомере буе эшли, өстенә кияренә ыштаны да юк бичараның.

А. Х.: Хәзерге заман язучысының да хәле шулаерак.

Р. Н.: Синеңчә, җөмләдә ни өчен өч нокта куела да, сөйләшкәндә ни өчен пауза ясала?

А. Х.: Сүгенмәс өчен...

Р. Н.: Бәхет бардыр ул, бигрәк тә "Бәхетле" кибетендә...

А. Х.: Равил Шәрәфи бу соравыңа: "Бәхетле"гә кергән идем, үземне бик бәхетсез итеп сиздем, — дип җавапны күптәннән әйткән иде инде.

Сергей АНДРИАНОВ



Илдар НӘФИЕВ



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

• Күкрәкләрен, иреннәрен зурайтты, ә баш миенә акчасы җитмәде...

• Суга тарифлар турында сөйләшәм дип барган иде, ә анда – авызларына су капканнармыни!..

• Хатыныңны тыңла, тёщаң әйткәнне эшлә...

• Акча янчыгын ачып күрсәткәч, операцияне кичектереп торырга булдылар...

• Күптәннән билгеле фал: әгәр дә кунакның аяк киемен очлы башы белән ишеккә таба куйсаң, ул озак тормый...

• Нәчәлник һәрвакыт хаклы... ләкин эш вакытында гына.

Александр ЭЗЕКОВ



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ

СӨЙЛӘШҮЛӘР

– Авыру, сез тартасызмы?

– Юк.

– Эчәсезме?

– Юк, эчмим.

– Нәрсә җүләр кебек елмаеп утырган буласыз, барыбер нәрсә дә булса табам бит!

• • •

–Исәнмесез, доктор!

– Исәнмесез, авыру!

– Нигә сез мине авыру дип уйлыйсыз?

– Ә мин нигә доктор булыйм, ди?

• • •

– Доктор, доктор! Сез миңа нинди озын диагноз язасыз?

– Борчылмагыз, бу диагноз түгел, бу – некролог...

• • •

– Авыру, сез миңа нишләптер ошамыйсыз әле...

– Сез дә, доктор, алма кебек матур түгел лә...

• • •

– Карагыз, үлә бит!!!

– Шулкадәр дулкынланмагыз сана! Әнә, андыйлар бездә бүлмә тулы...

• • •

– Доктор, мине монда беркем дә җитди кабул итми бугай!

– Нәрсә, шаяртасызмы!



Эрнест ДЫШАЕВ

Кичектерелгән картлык

Болганчык туксанынчы елларда бер моңсу мәзәк бар иде: әбинең пенсиясен карак урлаган һәм аңа яши алмаган. Ул заманнардан соң яше җитеп эшсез калган халыкның тормышы яхшы якка таба үзгәрде дип әйтеп булмый. Ләкин өметсез авыр еллар пенсионерларны дәүләт тамызган тиеннәргә яшәргә генә түгел, ә аларны бераз җыеп барырга да өйрәтте. Шуңа күрә азгын нәфесле бәндәләр махсус рәвештә картларның "кара көнгә" дип калдырган акчаларын кулга төшерүнең яңадан-яңа ысулларын эзлиләр. Юка пенсионер янчыгын чистартуның билгеле ысуллары әллә ни күп түгел, тик шулай да тормыш тарафыннан күп мәртәбәләр кагылган һәм аңа да карамастан беркатлылыгыннан арына алмаган өлкән буын һаман оста итеп куелган ятьмәләргә эләгә тора.

Мошенникларның пенсионер фатирына керүнең иң гади ысулы – берәр оешма хезмәткәре булып кылану: собес, пенсия фонды, газ йә электр челтәре... Ике "газовик"ның изге теләкләренә ышану бер Чистай пенсионерын аларны өенә кертергә мәҗбүр иткән. Берсе счётчик күрсәткечләрен "алган" арада, икенчесе түләү квитанцияләрен караштыргалаганнан соң, абзыйга аның мең ярым сум артык түләве турында хәбәр иткән. Һәм шунда ук аңа ике меңлек сузган. Бабай, шатлыгыннан нишләргә белмичә, сдача алырга дип, акчасын яшергән җиргә кереп киткән. Нәтиҗәдә, пенсионер 20 мең сумыннан колак каккан.

Чаллыда да шундый ук "тикшерү"дән соң өч абзый саклап тоткан акчаларын югалтканнар. Урланган суммалар 15 тән 137 мең сумга кадәр булган.

Чакырылмаган кунаклар, гадәттә, иң сизгер нәрсә – сәламәтлеккә басым ясарга яраталар. Берәр нинди гади генә, мисал өчен, массаж ясый торган приборны мошенниклар яшерен хәрби заводта эшләнгән һәм бөтен авыруларны да дәвалый торган җайланма дип тәкъдим итә алалар. Иң мөһиме – прибор әйбәт тавыш чыгарсын һәм бәясе яхшы товарныкы кебек югары булсын. Казанда яшәүче бер хатын нәкъ шул кармакка каба. Аңа 30 мең сумга радикулит дәвалаучы аппарат дип чәч ялтырата торган машинка "төртәләр". Ул берникадәр вакыт аның белән хәтта дәвалана да. Оныгы килеп чыгып, әбисенең күзләрен ачкач кына бөтен нәрсә ачыклана.

Шулай ук туганлык хисләрендә уйнау да киң файдаланыла. Яраткан оныкларын тормыш катлаулыкларыннан коткару хакына соңгы киемнәрен салып бирергә әзерләр бит. Әлмәттә яшәүче 87 яшьлек пенсионерга аның Ростовта яшәүче оныгы исеменнән таныш булмаган ир кеше шалтырата. Еларга җитешеп, юлда кеше таптатканы һәм җинаять эшен туктатыр өчен 240 мең сум кирәклеген хәбәр итә. Олы җанлы бабай, әлбәттә, акча табып бирә: бер өлешен кеше аша, икенче өлешен банк картасы аша тапшыра.

Әйтергә кирәк, банк картасы белән файдаланучылар да игътибарсыз калмыйлар. Казанда яшәүче пенсионер, телефон номерының блокировкалануы турында СМС алгач, килгән "разблокировка" инструкцияләре буенча билгесез счётларга 800 мең сум күчерә. Ә аның 71 яшьлек якташына генераль прокуратурадан шалтыраталар. "Прокуратура хезмәткәре" пенсионерга Интернет аша товар сатып алган өчен ярыйсы гына компенсация тиеш, дип хәбәр итә. Прокуратура начар әйбер әйтмәс, дип уйлап, абзый телефондагы егеткә үзенең карта мәгълүматларын хәбәр итеп, миллион сумнан колак кага.

Ул мошенникларны тоталармы, юкмы – картларның хәле аннан үзгәрмәячәк. Алар өчен иң зур кайгы – кешеләргә ышанычны югалту. Бер юаныч бар: әгәр картлыкка дип җыйган акчалар юкка чыккан икән, димәк картлыкны кичектереп торырга сәбәп бар.

Людмила САФИУЛЛИНА



Сергей ЕРМИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



НӘНИЛӘР СӨЙЛӘШӘ

– Әни! Ә мультимиллионер, ул, мультфильмнар ясап баеган кешеме?

• • •

– Әбекәй! Бакчада Айгөлгә мин генә ошыйм...

– Нигә алай дип уйлыйсың?

– Чөнки ул мине генә кыйнамый!



Илдус АЗИМОВ



Александр СЕРГЕЕВ

• • •

– Әни, кил әле монда! Мин баскычны аударДЫМ!

– Әтиең күрсә кирәгеңне бирә бит!

– Күрде инде! Ул, әнә, люстрада асылынып тора.

• • •

5 яшьлек Артур көтелмәгән сорау бирә:

– Ә бүгенге көн — ул кичәге иртәгәме?



Илдус АЗИМОВ

• • •

Гаилә фоторәсемнәре карап утырабыз.

– Ә монда без әтиең белән сине бала тудыру йортыннан алып кайтабыз, – дип аңлатам кызыма.

– Сез анда мине ник илттегез соң?

• • •

Кызым белән тәрбияви әңгәмә алып барам.

– Әни, – ди ул күңелсез генә, – җитәр инде сөйләшергә. Әйдә, гәпләшеп алыйк...



Фирдәвес ЗАРИФ

ОНЫТЫЛГАН МӘХӘББӘТ

Рудольф эшләгән оешмага бер хатын эшкә килде. Дөрес, алар оешмасына килүче һәм китүчеләр булгалап тора анысы...

Рудольф аларга әллә ни игътибар итеп тә тормый иде. Әмма монысы... монысы артык чибәр иде шул!

Рудольф аңа беренче күрүдә үк гашыйк булды. Элегрәк, шулай да була, дисәләр, ышанмас та иде: ни әйтсәң дә яшь вакыты түгел, кырыкка җитеп килә бит. Анысы шулаен шулай да, әмма йөрәк дигәнең моны һич кенә дә аңларга теләми. Тәмам чарасызлыкка төште Рудольф: чибәркәйне күрүгә, малай-шалай кебек кызара, сүз кушарга да кыймый, хәтта тегесе эш буенча сөйләшкәндә дә әйтер сүз таба алмый ык-мык килә.

"Җитте! – диде беркөнне Рудольф үз-үзенә. – Ирме син, әллә чирме?! – Бүген үк очрашуга чакыр". Һәм юк йомышын бар итеп, ул эшләгән бүлеккә керде.

– Исәнмесез, Рәйсә Хәсәновна, – диде Рудольф комачтай кызарып. – Ни, менә, Сезнең белән киңәшәсе бар иде.

– Хәерле көн, Рудольф Халикович! Әйдәгез, бүлмәгә рәхим итегез.

– Анда ук узып тормам инде. Кешеләр дә бар дигәндәй. – Һәм ул төнлә уятып сорасалар да әйтеп бирә алган нәрсә турында киңәш сораган итте. Тегесе һич кыенсынмый җентекләп аңлатты.

– Рәхмәт, Рәйсә Хәсәновна. Яхшылыгыгызны онытмам. Ни, эштән соң вакытыгыз булса, бәлки ресторанга кереп сөйләшеп утырырбыз.

– Ничегрәк булыр икән соң ул, Рудольф Халикович? Без әле юньләп таныш та түгел бит, – диде Рәйсә бөтен йөзе белән елмаеп. – Азрак уйларга вакыт бирегез инде, яме. Җавапны кичке якта бирермен.

– Рәхмәт, – диде Рудольф башка сүз таба алмый.

Рәйсә сүзендә торды, эштән китәргә ярты сәгать кала, шалтыратып, өч кенә җөмлә әйтте: "Урамда очрашып йөрергә без инде бала-чага түгел. Сәгать алтыга мин яшәгән фатирга – Нариман урамындагы бишенче йортка килегез. Тугызынчы подъезд, алтынчы кат, 347 нче фатир".

Затлы костюмын киеп, роза чәчәкләре тотып әлеге йортка килгәндә алты тулырга биш минут иде.

Гадәттәгедән дә матуррак күренде аңа Рәйсә. Өстендәге зәңгәр җирлеккә ак борчаклы күлмәге, гадәти булмаган серле күз карашы ничектер таныш тоелды Рудольфка. "Тукта, кемне хәтерләтә соң бу караш?!"

Ул арада Рәйсә залга карап дәште:

– Улым, чыгып кер әле монда. – Зал яктан яшүсмер егет чыкты.

– Исәнмесез, абый, – диде ул Рудольфка тартынып кына.


– Улым, таныш бул, бу синең әтиең була!

Рудольфның тез буыннары йомшады, маңгаена тир бәреп чыкты. Гүя бу минутларда аңа яшүсмер түгел, ә үзенең яшьлеге карап тора иде.

Эрнст ГЕЛЬМС, «Чаян» № 4, 1956



– Диссертациям начар дип әйтергә ничек телегез әйләнә? Аны минем иң шәп хезмәткәрләрем язды.



– Браконьерларны без менә шулай куркытабыз...

Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 23, 1974

ТУФАННАР КҮП ТҮГЕЛ

Күпләрнең уфтанып сөйләгәннәрен ишетеп һәм үзем дә аның күптәннән юклыгына күенеп яшим. Бер уйласаң, кем инде ул миңа? Туганым да, дустым да түгел. Чордашым дисәм — өлкәнрәк; якташым дисәм — ераграк, әмма әсәрләрен укыгач, мин аңа якынаям, фикерләр уртаклыгын тоям, карашларыбызның үткенлеген сизәм. Ләкин мин аңа тиңләшәм дип әйтә алмыйм. Хакым юк. Аның югарылыгына җитәр өчен Туфан булу кирәк. Ә ул, үзен генә түгел, Туфанлыгын булдырып, тагын бер Туфан булган Туфан! Фанилыкта даһиланып йөрүчеләр байтак. Ләкин аларның исемнәрен вакыт дигән нәрсә юып ташлый. Туфан Миңнуллин кеше атамасы гына түгел шул! Ул — татар әдәбияты атамасы! Бөек Татар милләтенең драма атасы!

МАКТАУДАН КОТКАРДЫМ

Туфан абый Миңнуллинга 75 яшь тулган бер кичә хәтердә. Түбән Камада "Җидегән чишмә" әдәби-музыкаль берләшмәсенең аңа багышланган зур тантанасы бара. Сәхнәдә бер-бер артлы мактау сүзләре белән сәнгать әһелләре һәм төрле оешма җитәкчеләре чыгыш ясый, аларны аралаштырып җырчылар, биючеләр, нәфис сүз осталары юбилярны котлыйлар. Бөек әдибебез, инде озакка сузылган мактаулардан талчыгып, ләкин бу халәтен тамашачыга сиздермәскә тырышкан кыяфәттә түзеп утыра. Менә сәхнәгә чираттагы сәнгать әһелебез, үзенең "күп" сөйләве буенча дан тоткан Әхсән Фәтхетдинов чыкты. Китте-китте тезеп: "Туфан Миңнуллин, СССР язучылар әгъзасы, СССР халык депутаты... Биш минут шундый дәрәҗәләрен тезеп, ... элеккеге ДОСАФ члены, элеккеге пионер..." дип тәмамлады һәм иҗатына күчте. Иҗатының нечкәлекләрен Күк һәм Җир белән бәйләп, Кешеләргә ябыштырып чыкты. Моңа ярты сәгать вакыт үтте. Инде әдипнең халәтен йорт ияләре белән бәйли башлагач, халык кул чаба башлады. Ул, охшаттылар, ахрысы, сөйләвемне дип аңлап, тагын да ялкынланыбрак, аның тормышын арткарак чигереп, өч яшьлек бала чагына кайтып төште. Нык белә ул Туфанны, бик нык белә!.. Халык тагын кул чаба. Юбиляр уңайсызлана. Кичәне алып баручылар, кыскарту кирәклеген белдереп, ишарә дә ясап карыйлар. Файдасы юк. Сәхнә артындагылар: "Чыгып әйт әле, — дип мине котырталар. Нишлим, чыктым да: "Әхсән абый, Туфан агага 80 тула бит инде!" — дидем. Зал алкышлардан шартлады, Әхсән, кулын селтәп, миңа иярде. Туфан абыйның шатланганын күрсәгез?!. Кешене шатландыра белү — зур бәхет бит ул.

Алмаз ХӘМЗИН

ТУФАН МИҢНУЛЛИН ҮЗЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘГӘННӘН.

ИКЕ ТУФАН

Хәсән Туфанның 70 еллыгына багышланган бәйрәм мәҗлесендә Туфан Миңнуллин әйткән шәраб алды сүзе:

— Хәсән абый, мин тугач та, мең тугыз йөз дә утыз бишенче елда, Сезнең хөрмәткә әти миңа Туфан исеме куйдырткан. Сез, Туфан абый, иҗатыгыз белән дә, яшәешегез белән дә минем исемгә тап төшермәдегез, олуг рәхмәт Сезгә, олуг шагыйрь Хәсән абый Туфан!

Хәсән Туфан үзе, Туфан Миңнуллин янына килеп, кулын кыскан.

БАТУЛЛА







Зөлфәт Хәйруллин шаржлары

Габделхак ӘХМӘТ

ЯВЫЗ ИВАНГА ҺӘЙКӘЛ КУЮ УҢАЕННАН

(Памфлет)

Шау гөр килә халык, нәрсә булган?
Йөгерәләр шашып, ашкынып,
Икән диләр Явыз Иван кайткан,
Тимер атка атланып.

Мин дә киттем әле күрергә дип,
Шул "терелгән" салкын мәетне,
Әйе кайткан, кылыч, тәре тотып,
Ташламаган иске гадәтне.

Кемне куркытам дип кайттың соң син?
Синсез дә күп бүген палачлар,
Алар синнән күпкә усалырак,
Сине алар санга сукмаслар.

Кайткан икән, нигә шаккатырга,
Тик шулай да торам уйланып,
Торсын димен, мәңге постаментта,
Явызлыкның символы булып.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ

КАЗАН ПАТШАЛЫГЫ ТУРЫНДАГЫ ТАРИХ

(Урыс елъязмасы битләреннән)

Канга туймас ерткычлар йөри иснәнеп,
Йортларда, мәчетләрдә канга кинәнеп.

Картмы, яшьме, табылса да берәү генә,
Шунда ук хәнҗәр кадыйлар күкрәгенә.

Яшь хатыннар, йә сылу кызлар котыла,
Йә кучәрдән дә түбән сабыйлар кала.

Бөтен җирдә өелгән мәет таулары,
Елга, чокыр, кое, урман канаулары.

Канлы үлек белән капланган йорт-нигез,
Өелгән гәүдәләр койма белән тигез.

Казансу, Болак буйлары, болынлыклар,
Гәүдә таптап ат чапмый — канлы тояклар.

Атлана урыслар ял иткән атларга,
Тагын тотыналар кан-мәет таптарга.

Урамнарда яшьле кан елгасы ага,
Яңгыр суларыдай — чокырларга таба.


Күл, елга, коелар кызыл — аккан каннан;
Исәннәр җиде көн су эчалмый аннан.


Көн дә таңнан төнгәчә барган бу суеш —
Дөньяда тиңе булмаган вәхши сугыш...



РӘСЕМНӘР һәм РӘССАМНАР










Вячеслав БИБИШЕВ



Максим СМАГИН



kartinka.ru



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хатыннар – рәхмәтсез җаннар. Мин "Рәхмәт малай/кыз өчен!" дигән мендәгән язулы машиналарны күрдем, ләкин шунда, күңел өчен генә булса да, ник берсе "Үзеңә дә рәхмәт!" сүзе язып ябыштырылганнары булсын.

• • •

– Доктор! Ярдәм итегез! Коткарыгыз! Мин сезгә күпме кирәк шулхәтле түлим!

– Яхшы. Ләкин акчасы – алдан! Югыйсә менә болай килеп чыга: кешегә булышасың, ә ул соңыннан мине белмәгән-күрмәгән кыяфәт ясап, табутта ята.

• • •

– Чибәркәй, туңдырма телисеңме?
– Юк, мин туңдырмаганны телим!

• • •

Минем әбием алтмыш яшьтә көненә бишәр километр йөри башлады. Хәзер аңа туксан җиде – без аның кайда икәнен дә белмибез.

• • •

Татар блондинкасы кадрлар бүлегендә анкета тутыра. "Род занятий" дигән графага җитеп, бик озак уйга кала. Аптырагач, язып куя: "Тудырганым булмады. Бераз шөгыльләнгәләдем".

• • •

Дәвахәнә табибы:
– Мин авырып киттем, ахрысы.
Шәфкать туташы:
– Үзегезгә үзегез диагноз куегыз да дәваланыгыз.
– Юк. Әйбәтрәк табибка барып күренәм.

• • •

– Ир кешенең йөрәгенә юл ашказаны аркылы үткәнне беләсезме?
– Булмаганны сөйләмәгез әле! Ирегез сөяркәсе янына токмачлы аш ашарга йөри дип уйлыйсызмы әллә?!

• • •

Кулинария хәйләләре. Әгәр итальяннарның спагетиларына украин борщын салып бутасаң, үзбәкләрнең яһүд фамилияле лагман ашамлыгы килеп чыгачак.



ЙӨЗ УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ ТУР



ПАРОВОЗГА ӨЕЛГӘННӘР

Бар иде шулай, җитмешенче елларда, поезд вагоннарын бал кортлары сыман сырып, утырып йөргән чаклар. Әлбәттә, болай ук түгел иде, ләкин әлеге бирем шул елларны, шул вакытларны хәтерләтә. Һинд киноларын караганда да очраштыргалый иде андый сюжетлар. Болай, ныгытыбырак баксаң, шул фильмнарның берсеннән алынгандыр әле бу шаккаттыргыч күренеш. Каян булса да, "Чаян" күнекмәсенә эләккәч, укучыларыбызның кайбер шаян карашларын журналыбызда яктыртыйк әле.

"Рәсәй эшсезләре Германия чигендә", — дип шөбһәле уйдырма-шаярту язып җибәргән "Күнекмә"бездә даими катнашучыбыз, Губаха шәһәрендә яшәүче А. Летов. Ходай күрсәтмәсен, дияргә генә кала безгә. **"Тимер юлчылар көнендә табигатькә сәфәр"**, — дигән язма да бар. Монысын үзе тимер юлчы булып эшләүче Нияз Саттаров җибәргән. СМСкасына Әгерҗедән дип куюы — шуңа дәлил. **"Рубин" җанатарлары яраткан командасына көч бирергә баралар"**, — бу фикер Казанда яшәүче К. Исмәгыйлевнеке. **"Поезд ватылган, ә төшеп этүче юк"**, — ди Шәмсия Таһирова. Шулай бугай шул, поездлары тик тора. Түбән Камадан килгән мондый фикергә без дә кушылабыз. **"Кешеләрне иртәнге электричкадан да ныграк таныштыра торган башка урын юк ул"**, — дип чын хакыйкатьне язып җибәргән Питрәч кешесе М. Жиһаншина. **"Электричкаларны кыскарту программасы менә нәрсәгә китерергә мөмкин"**, — дигән тәнкыйтьле нәтиҗәгә килгән Краснодар шәһәрендә яшәүче Ю. Горбачева. **"Мәскәү–Казан арасын өч сәгатьтә узачак поездны тизрәк ходка җибәрсеннәр иде инде"**, — дип хыялланып ята, ахрысы, мәскәүле В. Сорокин. Без дә көтәбез ул поездны, иптәш Сорокин. **"Меркель апайга кунакка"**, — монысын А. Летовның шөбһәле шаяртуына караганда, уңышлырак, йомшаграк нәтиҗә дип әйтергә кирәк. Чистайда яшәүче Е. Астафьевның җавабы күпләрнең күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. Шундый ук эчтәлектәге шаяртуга тартым кузаллау бар: **"Трамп чиккә койма куйганчы штатка барып җитәргә иде"**. Лаеш районындагы Комлы Кавәл авылы кешесе А. Ногаевның бу төрткеле җөмләсен шаяртучылар арасындагы ярышта югары урын тота дип бәяләргә кирәктер. **"Турыдан-туры Гиннесс китабына"**, — дигән күрсәтмә — кызыклы да, шулай ук бик уңышлы дип саныйбыз. Бу кызыкка кызып киткән Ульяновск шәһәрендә иҗат итүче даими шагыйребез – Зөфәр Батыров шигыре белән шаяртуларыбызны йомгаклап куйыйк.

Булды инде заманында
Ярлы чаклар, бай чаклар.
Гуманитар ярдәмме бу,
Әллә кача чакаклар?

Инде сезне яңа "Күнекмә"безгә рухландырабыз. Шулай, үзара, шаярышып, елмаешып-көлешеп яшик әле!





Александр КОСМЫЛИН




Виктор ФЁДОРОВ




Генрих БЮТНЕР (Германия)






Еш кына немецларда юмор хисе юк, дигән фикер ишетергә туры килә. Карикатурачы Генрих БЮТНЕР үзенең иҗаты белән бу фикерне тулысынча кире кага.












КҮҢЕЛСЕЗ ИРТӘ






























Александр АЛЁШИН



ГАРИП СЫННАР ПАРКЫ

Кадерле Чаян! Элек паркларны гасырлар буенча җитәрлек сыннар бизи иде. Ә хәзер алар берничә ел тору белән таркала башлый...

Шәрә сыннар гаугасы бетмәс борын, халыкны икенче бер мәсьәлә борчый, ул да булса сыннарның уалып коелуы. Бер сын бөтенләй постаменты-ние белән кыйшаеп аварга тора. Әлбәттә, шәһәр халкы балаларын шәрә сыннар янына алып килмәскә тырыша, ләкин бөтен бала артыннан күзәтеп бетереп булмый. «Авышкан түти» (шәһәр халкы әлеге сынга шундый исем бирде) берәрсенең башына килеп төшсә? Ярый ла ул аварга торган сынны урнаштырырга рөхсәт биргән түрә булса...

Р. САБИРОВ

ЯШЕЛ ҮЗӘН





КОСМЕТИКА КАПКЫНЫ

Хөрмәтле Чаян! Бушка сыйрның кайда ятканын барыбыз да белә. Шулай булуга да карамастан, әледән-әле хәйләкәр "капкын"га эләгә торабыз. Ничек эләкмәскә, ди, реклама нинди генә кызыктыру чаралары уйлап тапмый. Бигрәк тә хатын-кыз косметикасы булса.

Күптән түгел исемем белән эндәшеп, миңа бер хатын-кыз шалтыратты. Медициина иминиятләштерү полисыннан алган икән минем телефон номерымны. Бушлай косметика процедурасы үтәргә тәкъдим итте бу. Ләкин бер процедура белән генә чикләнеп булмый икән, калганнары – түләүле...

Әлеге сәер тәкъдимне кире кагырга минем акылым җитте җитүен, ә менә дус кызым килеп эләккән әлеге "капкын"га. Салонга кызыктырып китереп, оста гына реклама алымнарын кулланып, аны 60 меңлек тылсымлы сандыктагы косметиканы кредитка алырга мәҗбүр иткәннәр. Ә барысы да медицина иминиятләштерү полисыннан алынган шалтыратудан башланды...

Г. ҖӘЛӘЛИЕВА

КАЗАН


СЕРЛЕ ЧЫБЫК

Чаян дус! Авылның ун баганасы яңа яктырткыч утлар белән җиһазландырылган булуга карамастан, караңгы төшүгә, капшана-капшана, кесә яктырткычларын кабызып йөрергә мәҗбүрбез. Ә утны тоташтырган кеше юк әле... Җирле хакимияткә дә бер генә мөрәҗәгать итмәдек. Аңлатуларына караганда, эш ниндидер мөһим булган бишенче чыбыкта икән.

Нинди чыбык, кайчан куелачагын әле беркем дә белми. Ләкин ут челтәренә тоташтырган өчен 150 мең сум булганы беркемгә дә сер түгел. Әмма дөм караңгы авылга әлеге акчаларны таба гына алмыйлар...

БАЙДАНКИНО авылы халкы

ТҮБӘН КАМА районы



БАШЛАРЫ ЭШЛӘМИ

Кадерле Чаян! Газон һәм клумбалар тоткан һәм үстергән өчен миллионлаган сумнар түгүләре борчый мине. Алар бит инде күптән автостоянка ролен үтиләр. Бәлки анда асфальт кына җәяргәдер? Арттырасың, дип уйлый торгансыздыр? Алай булганда, Ямашев проспекты белән Адоратский урамы киселешенә күз салыгыз. Газонда кышынҗәен нинди генә маркалы машиналар тукталмый. Нигәдер ГАИ хезмәткәрләренең штраф чәпәргә таяклары гына күтәрелми. Асфальт җәеп куйсаң әйбәтрәк булыр иде. Рәхәтләнеп акчасын җый, керемле эш ич...

Р. АРСЛАНОВ

КАЗАН



Михаил ЛАРИЧЕВ

Кем ул анда?
Үзебезнекеләр...

Бүген халыкара
коррупция белән көрәш көне!
Иртәгә бирерсез!

Александр АЛЁШИН



Эрнест ДЫШАЕВ



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хатын-кызның кәефен кулына карап белеп була. Мәсәлән, әгәр ул кулына уклау тотып карап торса – димәк, аның ачуы чыкканлыгы аермачык...

• • •

Газетадагы белдерү:
"Бик зыялы гаилә фортепьяно сата. Ату калидорда комачаулап тора".

• • •

– Французлар, өстәл артыннан җиңелчә генә ашап, бераз туймыйчарак кузгалырга кушалар.
– Ә син, нәрсә, француз мәллә?
– Юк.
– Алайса, әйдә, утыр, рәхәтләнеп тыгынабыз...

• • •

Безнең офиста чибәр кызлар шулкадәрле күп, теләсәң-теләмәсәң дә теләрсең...

• • •

Яһүд алтын балык тоткан. Тегесе әйтә:
– Җибәр мине. Мин барлык теләкләреңне дә үтәрмен...
– Урыс буласым килә! – ди икән яхүд.
– Яхшы! – дигән балык һәм аны Израильгә җибәргән.

• • •

Хатыны ире янына төрмәгә килгән:
– Монда үзеңне ничек хис итәсең?
– Нәкъ өйдәге кебек инде: беркая да чыгармыйлар, ашатулары да – ташка үлчим.

• • •

– Сез өйләнгәнме?
– Аерылышкан.
– Нык аердылармы?
– Бер чемодан калдырдылар...

• • •

– Син койкалы балык әзерли беләсеңме?
– Аны әзерләү бик җиңел. Бер кисәк кипкән балык, бер йотым сыра...

• • •

– Димәк, миннән биш мең доллар әҗәткә алып тормакчы буласыз. Кире кайтарып бирү вәгъдәсен бирәсезме?
– Мин сезгә бик тә намуслы кешенең сүзен бирәм!
– Яхшы, сезне бүген кич әлеге кеше белән бергә килүегезне көтәм.



Заһир ХӘКИМОВ



Алексей МАМАЕВ



Александр ЛЕВИТИН

ӘБИ ПАТШАНЫ НИЧЕК КАРШЫЛАГАННАР

Казан гомер буе үзенең кунакчыллыгы белән дан тоткан. Монда һәрвакыт ханнардан алып генсек һәм президентларга кадәр шәхесләрне юмарт итеп кабул итә белгәннәр. Тик 1767 елда Екатерина II не каршылавы белән Казан, чын мәгънәсендә, тарихка кереп калган.

Екатерина II юлда булуны бик яраткан һәм сәяхәтләрен әһәмиятле дәүләт эше дип санаган. 1767 елны, дәүләтнең көнчыгыш өлкәләре белән якынрак тынышу теләге белән, императрица 25 корабль һәм ике мең кеше белән Идел буйлап зур сәяхәткә чыга.

26 майда патшабикәнең дүрт зур көймәсе Казан Кремле ярына килеп туктый. Асыл кунакны монда тантаналы рәвештә каршы алалар. Шәһәргә алып баручы юлга кызыл постау җәелгән була. Екатеринаны меңләгән казанлылар сәламли. Патша каретасының янәшәсендә атка атланган Казан губернаторы белән генераллар бара. Юлның ике ягы буйлап ак киемнәр кигән христиан руханилары белән семинаристлар тезелеп тора һәм махсус рәвештә бу вакыйгага багышлап язылган шигырь-җырларын көйли. Кремль урамында байрак тоткан гарнизон батальоннары барабан кагып тора.

Шәһәргә патшабикә махсус төзелгән кеше буендагы алтынланган сыннар белән бизәлгән триумфаль капка аша керә. Грузин урамында (хәзерге К. Маркс ур.) тагын бер шундый ук капка була. Шәхси хатында Екатерина хәбәр итә: "Без олуг патшалыкның мәркәзе булырдай калага килеп кердек; искиткеч кабул иттеләр; дүртенче атна рәттән бөтен җирдә бер үк төрле шатлык күрәбез, ә монда тагын да яхшырак... Мондагыдай триумфаль капкаларны минем беркайда да күргәнем юк иде..."

Кичләрен шәһәр бик шәп итеп яктыртыла һәм фонарьлар белән бизәлә, ә урамнар буйлап, бу гүзәллеккә сокланып, казанлылар йөри. Хәллерәкләре юмартлык һәм кунакчыллыгы белән бер-берсен уздырырга тели. Екатерина II бу турыда: "Әгәр мөмкинлек булса, шәһәр кешеләре үзләрен келәм урынына җәярләр иде..." – дип яза.

Патшабикәне озату хөрмәтенә губернатор йортында (хәзерге КАИның 7 нче корпусы бинасы артында) халык бәйрәме оештырыла. Монда императрицага Казан губерниясендә яшәүче төп халыкларның вәкилләре милли киемнәрдә күрсәтелә. Бу бәйге "таулар һәм зур ташлар өстендә" оештырыла. Үзенең көндәлегендә Екатерина болай дип яза: "Әгәр дә теләсәк, Казанда без ай буе унтугыз балда биеп йөри алган булыр идек, – моны күргәч, бездә башкалага кайту теләге юкка чыкты, бу зарур булмаса, эшнең нәрсә белән бетәсен әйтү кыен иде".

Баллар һәм маскарадларда күңел ачып йөргәннән соң, илбашы 1 июнь көнне шаулы яраннары, этләре һәм пешекчеләре белән кунакчыл каладан китеп бара. 1767 елның 29 маенда бер хатында ул: "...Бу шәһәр, һичшиксез, Россиядә Мәскәүдән соң беренче... Казанның зур патшалык мәркәзе икәнлеге күренеп тора", – дип яза.

Бу сәяхәт дәүләтнең беренче кешеләренең үз илләре буенча йөрү традициясен башлап җибәрә. Тик тантаналар һәм күңел ачулар хакимнәргә гади кешенең тормышын өйрәнергә мөмкинлек калдырмый. Хәтта үтә күзәтүчән Екатерина да "аерым җитешсезлекләр"гә генә игътибар итә ала – "җирәндергеч" итеп тәэелгән Түбән Новгород; "комсыз" Сембер; Казан архиерее Лука Канашевич тарафыннан вәхшиләрчә юкка чыгарылган изге мөселман һәйкәлләре...

Шулай да бу күзәтүләрнең соңгысы бик җитди нәтиҗәләргә китерә. Екатерина 1767 елда шәхси Указы белән татарларга мәчетләрне таштан салырга рөхсәт бирә – моңа кадәр аларны бары тик агачтан гына төзергә мөмкин була. Шуның белән беррәттән, манараларын кирәкле биеклектә ясарга рөхсәт бирелә. Урынлы хакимиятләр ризасызлык белдергәч, ул болай дип җавап бирә: "Мин аларның урынын җирдә билгеләдем, ә күккә алар кирәк кадәр күтәрелә алалар, чөнки күкләргә мин хуҗа түгел". Ә моңа кадәр Екатерина татар сәүдәгәрләрен хокуклары буенча рус сәүдәгәрләре белән тигезләп, аларга бөтен Россия җирендә сәүдә итәргә рөхсәт бирүче Указ чыгара. Бәлки императрицаның бу адымнары татар күңелен яулап алгандыр. Һәрхәлдә, рус патшабикәсенә әверелгән чыгышы буенча немец хатыны, безнең халык хәтеренә олы җанлы "Әби патша" булып кереп калган.

Айрат ШӘЙДУЛЛИН



Сергей АНДРИАНОВ

Терминал һәм криминал

Көчең булса, акылның кирәге юк дигән гыйбарә бөтенебезгә яхшы билгеле. Ә кувалда турында әйтеп торасы да юк. Инде куәтле шартлагыч матдәләргә килгәндә, аларга бернинди терминатор да каршы тора алмый, ә банк терминалларының көле күккә оча.

Берзаман көзге кичтә Чистайның тын урамнарын шартлау кайтавазы әйләнеп уза. Ишек төбендә утыручы әбиләр, җанланып, моның кем эше булуы турында фикер алыша башлыйлар: яшь хулиганнар, кара сакаллы террорчылар... Чынлыкта, барысы да бик гади булып чыга. Сәгать заводының капкасы янына килеп җиткән полицейскийлар җирдә таралып яткан ватык пыяла кисәкләре һәм шактый изелгән банкомат күреп ала. Ләкин билгесез калган шартлату осталары акчага барып җитә алмыйлар: җайланманың акча тартмасы исән булып чыга...

Чистайдагы шартлаудан соң берничә көн үтүгә, Казанда, Җиңү проспектындагы Сбербанк бинасында "күк күкрәп" уза. Бу юлы бомба белгечләренә "бәхет елмая": "эчәкләре чыккан" терминалдагы бөтен акчаны алар кырып-себереп алып китә. Сәетов һәм Оленинның криминаль тарихы шуннан башлана. Берничә ай эчендә алар берничә банкоматның "башына җитәләр" һәм кесәләренә алты миллион сумнан артык акча салалар. Җиңел табыштан башлары әйләнеп китеп, алар, гомумән, уяулыкны югалталар. Мәсәлән, Горький шоссесындагы терминалны Булат Сәетов... кувалда белән бәреп ватмакчы була! Ул, мавыгып, терминал белән көрәшкән вакытта иптәше Евгений Оленин, видеокүзәтү камераларына игътибар итмичә, машина эчендә сакта утыра. Шул язмалар буенча эзләренә төшеп, тиздән аларны тоткарлыйлар да...

Киң яңгыраш алган бу вакыйга шул ук ысул белән баемакчы кайберәүләрнең теләкләрен суытыр иде шикелле. Әмма яман үрнәк "йогышлы" булып чыга. Күптән түгел өч Казан егете Отябрьская урамындагы банкоматны отвёртка белән ачып, кесәләренә акча тутыра башлый. Ләкин көтмәгәндә полиция патруле килеп чыгып, "эшне боза". Егетләр качарга тырышып карый, тик ерак китә алмыйлар. Тикшерүчеләр белән аралашканнан соң, бу аларның беренче генә бушаткан терминаллары булмаганы ачыклана.

Элек хөкемгә тартылган 66 яшьлек абзыйның исә эше бөтенләй уңмый. Полицейскийлар аны Казанның Вахитов урамындагы банк фойесында монтировка ярдәмендә "акча тартмасын" ачарга маташканда күреп алалар. Акча аңа тәтеми, ә менә срок бирәчәкләрдер...

Ни дисәң дә, тиз һәм җиңел генә баеп китүгә беркем дә каршы түгел. Тик матди хәлләрен җиңаять юлы белән яшен тизлегендә хәл итәргә теләүчеләргә бер кисәтү: алар файдаланган коралларга каршы ысуллар җитәрлек. Кувалда белән шартлаткыч матдәләргә каршы да...

Айдар СУБАЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Николай ВОРОНЦОВ



Вячеслав ШИЛОВ



РЕКЛАМА



КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ

Сез "Чаян"ның сизелерлек дәрәҗәдә калынаеп киткәненә игътибар иткәнсездер бит? Чөнки ул хәзер аена бер тапкыр, ләкин ике тапкыр калынрак булып чыга. Калын "Чаян" элеккечә сезнең тугры һәм шат дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Татарстандагы укучылар "Чаян"га "Почта России" каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша язылa алалар. Бу очракта язылу индекслары русча – П2440, татарча П2438 булачак.



Сәрвәр ЖАНБӘКОВ

ТРУБКАНЫ КУЯМ...

Көне буе берөзлексез шалтыраудан телефоным кызып бетә. Беренче тапкыр иртәнге алтыда шалтыраталар:

— Өегезгә кайнар сумсалар китерәбез! Әле генә мичтән чыккан! Ташламалар белән...

— Китерегез, — минәйтәм, — булыр сиңа ташлама! Тугызынчы каттан. Сумсаларың белән бергә...

Һәм трубканы куям. Биш минут та үтми, тагын шалтыраталар:

— Мин — Аида, Швейцария косметология фирмасы вәкиле, — ди татлы хатын-кыз тавышы.

— Ә мин бай финанс магнаты Сорос, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм итәм...

— Бездә битне яшәртүче гаҗәеп крем бар. Хатыныгызга бик ошар дип уйлыйм...

— Юк минем хатыным. Тёща гына бар. Ә аны яшәрттең ни дә, яшәртмәдең ни...

Трубканы куям. Тик ул шунда ук тагын шалтырый:

— Махсус сезнең өчен, — ди миңа Левитан тавышы белән бер ир кеше, — уникаль тәкъдим ясыйбыз: елына кырык биш процент белән ике миллион сумлык кредит. Соңга кала күрмәгез!

— Зур рәхмәт, — дим, — тик мин ашыкмыйм әле. Бераз тыныч яшәп каласым килә...

Һәм трубканы куям. Бүлмәдән кухняга чыгарга өлгермим — тагын телефон шалтырый:

— Бу - "Иң зур тәрәзәләр" фирмасы. Без акция уздырабыз — пластик тәрәзә түләүле, ә форточкасы — бушлай.

— Форточкасы ябыламы соң?

— Әлбәттә!

— Алайса форточкаңны бернәрсә дә ишетелмәслек итеп ныклап ябып куй...

Тәбәмнең яртысын да ашарга өлгермәдем, тагын шалтыраталар.

— Ә сез краннан аккан суның зыянлы икәнен беләсезме? — дип гаҗәпләндерә мине хатын-кыз тавышы. — Ә бездә менә дигән фильтрлар бар. Кыйммәт тә түгел — бары тик йөз мең — һәм сез өч көн буе туктаусыз эшли торган җайланманың бәхетле иясе була аласыз.

— Ә мин су белән тәнлә генә файдаланам! — дип җавап бирәм мин һәм трубканы куям. Һәм шунда ук кире алам.

— Миндә сезнең өчен күңелсез яңалыклар, — дип хәбәр итә таныш булмаган тавыш. — Сезнең улыгыз машинада юл аша чыгып баручы карчыкны бәрдергән. Ләкин йөз меңгә полиция белән мәсьәләне хәл итәргә була. Акчагыз бармы?

— Акчам бар, — дим, — тик улым юк.

Трубканы куям. Тагын шалтырау ишетәм.

— Сезне собестан борчыйлар. Без иске мең сумлык акчаларны Казан, Севастополь, Владивосток сурәтләнгән яңа ике меңлекләргә алыштырабыз. Сезнең меңлекләрегез бармы?

— Юк. Йөзлекләр генә.

— Бик шәп! Безнең чегән хатыннарына охшаган хезмәткәрләребезне көтегез... Гафу итегез, сез үзегез кем буласыз?

— Белгечлегем буенча боксчы, дзюдо буенча тренер булып эшлим, штанга һәм винтовкадан ату белән мавыгам...

Ашыгып трубканы куялар.

ЗӘҺӘР БАШЫҢА ҖИТӘР

Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО




Сергей ЕРМИЛОВ





Юрий КУХАРЕНКО



Сергей АНДРИАНОВ



Вячеслав ШИЛОВ

ЧуАр пресса

РОБОТЛАР КИЛӘ!

Кытайдагы Шэньчжэн шәһәрендә хәзерге технологияләр күргәзмәсе ачылган. Анда балаларны өйрәтер өчен тиешле робот күрсәтелгән. Тик роботның электрон "баш мие" сыекланып киткән. Пыяла стендны ватып, ул күргәзмәгә килүчегә һөҗүм иткән. Зыян күрүчене хастаханәгә алып киткәннәр. Моңа карасаң, фантастик романнардагы машиналарның баш күтәрүе чынга ашарга мөмкин.

УЛ ЭЛЕК НИКИТА БУЛГАН

Сакал-мыексыз Никита Джигурда тагын бөтен халыкны шаккаттырырга уйлаган. Балаларына сәер исемнәр кушу гына җитмәгән (малае – Мик-Анжел Крист, кызы – Эва-Влада), ул үз исемен дә алыштырган. Хәзер ул – Джанатан Эль-Аир Браташ Джи Погоржельский фон Ган Эден.

Моны истә калдыру Исландиядәге Эйафьятлайокудль вулканы исеменә караганда да кыенрак.

ТҮЛӘ ҺӘМ ТЫНЫЧЛАП ЙОКЛА

Мәскәү астындагы Одинцово шәһәрендә яшәүче Александр Гончаренко салым инспекциясеннән хат алгач, телсез кала язган. Гадәти ике бүлмәле фатир өчен ул дүрт миллион налог түләргә тиеш икән. Калтыранган хәлдә Александр салым инспекторлары янына йөгергән. Алары, җыелышып, хатадан көлгәннәр һәм милек мөнәсәбәтләре министерствосына буталчыкны хәл итәргә җибәргәннәр. Бу эш тиз генә булмавы көн кебек ачык. Әлегә – тикшерү барганда, Гончаренко бурычлы дип исәпләнә.


ИЖДИВЕНЕЦЛАР

Бөекбританиянең салым ведомствосы бирәүдән графасы дөрес тутырылмаган өчен салым декларациясен кабул итмәгән. Эвешем шәһәрендә яшәүче "Иждивенецлар" графасында ул: "2 миллион иммигрант, 1,1 миллион наркоман, 4,4 миллион эшсез, 900 мең төрмәдә утыручы һәм өстәвенә, Парламенттагы һәм Европа комиссиясендә утыручы 650 юләр" дип язган.

Салым ведомствосында эшләүче мондый җавапның була алмавын әйткән. Гражданин "Мин кемне төшереп калдырганмын соң?" – дип ачыкларга тырышкан.







Отто ХОЙЗИНГЕР (Хорватия)




Клод БЕРТЭ (Бельгия)



Макс ЛУЧИНСКИ (Чехия)



БИЗАРРО (Франция)



Марек **РАЧКОВСКИЙ** (Польша)

Cartoonblues. com., BizarroComic.Blogspot.com



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Урам буйлап лаякыл исерек бара. Каршысына ментлар килеп чыга:

— Гражданин, фамилиягез ничек?

— Үзегез белегез менә! Беренче иҗеге — сәясәтчеләр вәгъдә иткән нәрсә, ә икенче иҗеге —чынлыкта булган нәрсә.

— Гражданин Райхер, әйдәгез безнең белән!

• • •

Гинеколог кабинеты каршында озын чират. Шунда кызу адымнар белән бик хәрәкәтчән ханым килә дә: "Мин сорап кына чыгам", — ди. Чиратагылар: "Ә без күрсәтәбез генә!" — дип җавап бирә.

• • •

Эштә начальнигым мәзәк сөйләде. Әй көлдем, әй көлдем шунда, хәтта караваттан чүт егылып төшмәдем...

• • •

— Бокс — спортның иң яхшы төре! Үлеп яратам шуны!

— Оһо! Сез, мөгаен, боксчыдыр?

— Юк, мин — дантист.

• • •

— Ничек сезгә кичәге төшке аш?

— Ничек дип әйтим икән? Әгәр аш шәраб кебек җылымса булган булса, ә шәраб каз кебек үк карт булса, ә каз хуҗабикә сыман симез булса, ул чагында әлеге сыйлану начар булмаган булыр иде!

• • •

Фатир ишегенә шакыган тавыш ишетелә. Тынлык. Тагын шакыйлар...

— Ачыгыз!

Һаман тынлык. Тагын шаку.

Ниһаять, фатир эченнән җавап бирәләр:

— Кем анда?

— Полиция!

— Уф-ф! Ә без авылдан туганнар килгән дип торабыз...

• • •

Участок табибы:

— Кайсы төшегез авырта?

— Монда.

— Ул урын минем участок түгел!

• • •

Телевизор нихәтле юка булса, анда күрсәткәннәр дә шулкадәрле юка.

Антон МАКУНИ

ТӨКЕРЕНҮ

Без ул кыз белән очраклы гына таныштык. Ул күпердән аска төкереп тора иде. Ә минем шул чакны астан үтеп барышым. Шалт – минем башка. Туктадым да өскә төкерергә тотындым.

– Син нәрсә, җүләр мәллә? – ди бу.

– Әйе, шыр җүләр! – мәйтәм, горурланыбрак.

– Каян килә шундыйлар? – дип аптырабрак әйтеп куйды кызый.

– Күпер астыннан... – дип җавап бирдем, моның килеш-килбәтенә күз салып.

Ул йөгереп кенә минем янга төште дә янәшәмә килеп басты.

– Син шулай төкерергә кайда өйрәндең?

Тавышында – көнләшү чаткысы.

– Зоопаркта. Дөя шулай төкерә. Ярты ел буе шунда йөрдем...

– Их, менә мин шуны белмәдем! – дип пошынды кыз.

– Аптырама, өйрәнерсең! – дидем аны канатландырып.

– Мин сине гомерем буе беләм шикелле! – диде кисәктән бу.

– Күз тидерерсең, төкереп куй! – Киңәш биргән булдым аңа.

– Тьфү-тьфү-тьфү! – дип, җилкәсе аша төкеренде ул. Һәм – Әйдә, безгә киттек, – диде.

Без аның өенә кердек. Ул шундук юыну бүлмәсенә кереп китте. Мин кызның авызына эләккән сабын күбеген төкерүен ишетеп тордым һәм тыныч кына чыгуын көттем. Ниһаять ул чыкты да, әдәп саклап тормый-нитми, миңа ташланды...

...Шуннан соң без кочаклашып түшәмгә төкереп яттык. Бераздан сикереп тордым да, бернәрсәгә дә әллә ни исем китмичә тиз-тиз киенергә керештем. Ул төкереп караган сыман гына минем киенгәнемне карап торды.

– Без тагын кайчан төкеренешәбез соң? – дип сабырсызланып сорап куйды кызый.

Мин, җавап бирмичә генә чыгып ычкынырга дип, ишекне ачтым.

– Төкерәм мин сиңа, – диде дә ул, сүзләренең чынлыгын раслап, лачт итеп миңа таба төкерде.

– Килеп җитмәде! – дидем дә үзенә төкердем.

Минем төкерүем әйбәтрәк килеп чыкты – чүтеки ярты ел буе дөядән өйрәнү юкка булмаган икән.







САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

1923 елдан чыга.
№ 18 (1854) 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Павел СТАРОВЕРОВ**
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Лайсан ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин.

Татарстанда яшәүче укучыларыбыз журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язына алалар.
Бу очракта язылу индекслары русча П2440, татарча П2438.
«Агентство «Роспечать» Каталогында индекслар: 73489 – рус, 73488 – татар телендәге журнал өчен.
Аның буенча Россия һәм Татарстан укучылары язына ала.

Айга бер тапкыр чыга.

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басарга кул куелды: 12.12.2016 ел.
Гомуми тираж –3010
(рус. – 1872 тат. – 1138)
Заказ М-3251
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1.
Учетн.-изд. табагы 3,1.



Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
татмедиа тел./факс: 222-05-54.

16+


E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Бәясе ирекле

СУРӘТВОРД

Фрагментлар буенча картиналарны табыгыз һәм аларның авторларының фамилияләрен шакмакларга тутырыгыз.





Картиналарның авторлары (сулдан-уңга): Серов, Суриков, Фешин, Гойя, Гро, Тьеполо, Моне, Васнецов, Врубель, Дега, Давид, Эйк, Поленов.

Уйна да, уйла да!

ГЕОВОРД

Горизонталь буенча:

















Вертикаль буенча:



Бирелгән атаклы символлар буенча шәһәр исемнәрен табыгыз. Алар буенча язып, вертикаль буенча символы ватылган чаң булган Венгриядәге шәһәр исемен укыгыз.

Горизонталь буенча: 1. Мәскәү. 2. Венеция. 3. Казань. 4. Брюссель. 5. Варшава. 6. София. 7. Бремен. 8. Хельсинки. 9. Берлин. 10. Рим. 11. Киев. 12. Копенгаген. 13. Нью-Йорк.

Рәсемнәрдә ун аерма тап




ЯҢА ЕЛ БҮЛӘКЛӘРЕ

Виктор ФЁДОРОВ





Игорь КИЙКО

Максим СМАГИН





Рушан ГАТАУЛЛИН

Валентин ДУБИНИН

